КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 26 декабрь г.Казань № 1215

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 26 гыйнвар, 42 нче карары белән расланган Икмәк пешерү предприятиеләренә социаль икмәкләр җитештерүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 26 гыйнвар, 42 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 5 март, 137 нче; 2018 ел, 4 сентябрь, 746 нчы; 2018 ел, 3 ноябрь, 979 нчы; 2018 ел, 21 декабрь, 1200 нче; 2018 ел, 28 декабрь, 1252 нче; 2019 ел, 12 февраль, 98 нче; 2019 ел, 24 май, 438 нче; 2019 ел, 9 июль, 559 нчы; 2019 ел, 18 сентябрь, 849 нчы; 2019 ел, 12 декабрь, 1141 нче; 2019 ел, 16 декабрь, 1151 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Икмәк пешерү предприятиеләренә социаль икмәкләр җитештерүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктның өченче абзацында «агымдагы финанс елының гыйнварында – июнендә» сүзләрен «агымдагы финанс елында» сүзләренә алыштырырга;

4 нче пунктның «а» пунктчасындагы өченче абзацында «банкротлык» сүзен «аңа карата банкротлык процедурасы гамәлгә кертелмәгән, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмаган» сүзләренә алыштырырга;

6 нчы пунктның дүртенче абзацында «банкротлык» сүзен «аңа карата банкротлык процедурасы гамәлгә кертелмәве, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмавы» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $8^1$ һәм $8^2$ нче пунктлар өстәргә:

«$8^1$. Субсидияләр бирүнең нәтиҗәсе – социаль икмәкләрне реализацияләүнең план буенча күләмнәренә ирешү.

$8^2$. Субсидияләр алучылар субсидияләр алган елдан соң килүче елның 1 февраленә кадәр кушымтада күрсәтелгән форма буенча субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисаплар кертә.»;

әлеге Тәртипкә кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Икмәк пешерү предприятиеләренә социаль икмәкләр җитештерүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә
кушымта

Форма

20___ елның ________ хәленә карата
субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында
ХИСАП

Субсидия алучы оешманың исеме:
_______________________________________________________________________

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Гомумроссия үлчәү берәмлекләре классификаторы буенча үлчәү берәмлеге | | Хисап көне хәленә карата күрсәткечнең ирешелгән мәгънәсе |
|---|---|---|---|---|
| | | исеме | коды | |
| 1. | Социаль икмәкләрне реализацияләү күләме | тонна | 168 | |

Субсидия алучы оешманың
җитәкчесе _________________ _____________________
(имзасы) (Ф.И.Ат.ис.)

Баш бухгалтер _________________ _____________________
(имзасы) (Ф.И.Ат.ис.)

20___ел, «___» ___________

Мөһер (булганда)

___________________________________